Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXIII-8**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 4 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге өченче затларның (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан гайре) хокукларыннан бәйсез булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнештәге мөлкәт исемлеген төзү, аны алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибен раслау турында

Аренда, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү шартларында муниципаль милектән нәтиҗәле файдалануны тәэмин итү максатларында, 2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 маддәсенең 4.1 өлешенә, 2018 елның 3 июлендәге “Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне көчәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы 185-ФЗ номерлы Федераль законга, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе 1 өлешенең 25 пунктына, “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы Федераль законның 18 маддәсенең 4 өлешендә күздә тотылган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 21 августындагы 645 номерлы карары белән расланган өченче затларның хокукларыннан бәйсез (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан гайре) федераль мөлкәт исемлеген төзү, аны алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Кагыйдәләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге өченче затларның хокукларыннан бәйсез (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт

хокукларыннан гайре) булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнештәге мөлкәт исемлеген төзү, аны алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару Тәртибен расларга (Тәртип теркәлә).

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 4 сентябрендәге
XXXIII-8 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге өченче затларның (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан гайре) хокукларыннан бәйсез булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү өчен билгеләнештәге мөлкәт исемлеген төзү, аны алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару**

**Тәртибе**

1.Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милкендәге“Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы Федераль законның 18 маддәсенең 4 өлешендә күздә тотылган, өченче затларның (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан гайре) хокукларыннан бәйсез мөлкәтнең (алга таба тиңдәшле рәвештә – муниципаль мөлкәт, исемлек) , шул исәптән ( шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, яшелчә, җиләк-җимеш үстерү бакчачылыклары, ялгыз торак төзелеше өчен билгеләнештәге җир кишәрлекләреннән гайре) җир кишәрлекләренең, йортлар, каралты-куралар, корылмалар, торак булмаган биналар, җиһазлар, машиналар, механизмнар, җайланмалар, кораллар, транспорт чаралары, инвентарьлар исемлеген төзү, аны (шул исәптән ел саен тулыландырып) алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгарудагы гамәлләр тәртибен муниципаль мөлкәтне озак сроклы нигездә ия булырга һәм (яки) файдалануга (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга бирү максатларында билгели.

2.Исемлеккә түбәндәге критерийларга туры килүче муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматлар кертелә:

а) муниципаль мөлкәт өченче затлар хокукларыннан бәйсез (хуҗалык алып бару хокукы, оператив идарә итү хокукы, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан гайре);

б) муниципаль мөлкәт кулланылышта чикләнмәгән;

в) муниципаль мөлкәт дини билгеләнештәге объектбулып тормый;

г) муниципаль мөлкәт тәмамланмаган төзелеш объекты булып тормый;

д)муниципаль мөлкәткә карата аны башка бер затларга бирү турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының карары кабул ителмәгән;

е) муниципаль мөлкәт Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруны фаразлау планына (программасына) кертелмәгән;

ж) муниципаль мөлкәт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләүгә тиешле дип табылмаган.

3.Муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматларны исемлеккә кертү (шул исәптән ел саен тулыландыру), шулай ук муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматларны исемлектән чыгарып ташлау Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының (алга таба – вәкаләтле орган) исемлекне раслау яки җирле үзидарә органнары, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мәнфәгатьләрен гәүдәләндерүче гомумроссия коммерциячел булмаган оешмаларның, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмаларның, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләренең, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының тәкъдимнәре нигезендә аңа үзгәрешләр кертү турындагы боерыгы белән гамәлгә ашырыла.

Исемлеккә муниципаль мөлкәтне чыгаруны күздә тотмаган үзгәрешләрне кертү муниципаль мөлкәт реестрына тиешле үзгәрешләр кертү датасыннан 10 эш көненнән дә соңармыйча гамәлгә ашырыла.

4.Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне карау вәкаләтле орган тарафыннан тәкъдим кергән датадан соң 30 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла. Тәкъдимне карау нәтиҗәләре буенча вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

а) әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән критерийларны исәпкә алып, тәкъдим кергән муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматларны исемлеккә кертү хакында;

б) әлеге Тәртипнең 6 һәм 7 пунктлары нигезләмәләрен исәпкә алып, тәкъдим кергән муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматларны исемлектән төшереп калдыру хакында;

в) тәкъдимне исәпкә алуны кире кагу турында;

5. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне исәпкә алуны кире кагу турында карар кабул ителү очрагында вәкаләтле орган тәкъдимне тапшырган затка муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматларны исемлеккә кертү яки муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматларны исемлектән төшереп калдыру мөмкин түгеллеге турында дәлилле җавап җибәрә.

6. Вәкаләтле орган муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматларны исемлектән төшереп калдырырга хокуклы, әгәр муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматларны исемлеккә кертү көненнән соң ике ел дәвамында бу мөлкәткә карата кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан яки кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык итү инфраструктурасын төзүче оешмалардан килеп ирешмәсә:

а) муниципаль мөлкәткә карата аңа ия булу һәм (яки) аннан файдалану хокукының күчүен күздә тотучы шартнамә төзү хокукына аукционда (конкурста) катнашуга бер мөрәҗәгать тә;

б) күрсәтелгән шартнамәне төзү 2006 елның 26 июлендәге “Конкуренцияне яклау турында”гы 135-ФЗ номерлы Федераль законда күздә тотылган очракларда аукцион (конкурс) үткәрмичә генә гамәлгә ашырылырга мөмкин булган муниципаль мөлкәтне бирү турында бер гариза да;

7.Вәкаләтле орган муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматларны түбәндәге очракларның берсендә исемлектән төшереп калдыра:

а)законнар белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль мөлкәткә карата аны муниципаль хаҗәтләр яисә башка максатлар өчен файдалану турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының карары кабул ителгәндә;

б) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының суд карары буенча яки закон белән билгеләнгән башка тәртиптә муниципаль мөлкәткә карата милек хокукы бетерелгәндә.

8. Муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматлар исемлеккә 2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 маддәсенең 4.4 өлешенә туры китереп билгеләнгән составта һәм форма буенча кертелә.

9. Муниципаль мөлкәт турындагы мәгълүматлар исемлектә территорияләрендә муниципаль мөлкәт урнашкан муниципаль берәмлекләр буенча, шулай ук мөлкәтнең төре (күчемсез мөлкәт (шул исәптән бердәм күчемсез комплекс), күчемле мөлкәт) буенча төркемләнәләр.

10.Исемлекне алып бару вәкаләтле орган тарафыннан электрон формада гамәлгә ашырыла.

11.Исемлек һәм аңа кертелгән үзгәрешләр тиешле:

а) расланган көннән соң ун эш көне эчендә http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында игълан ителергә;

б) расланган көннән соң өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга.